**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 июнендәге 2332 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 3514 номерлы «Совет районының Волочаевка урамындагы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 3514 номерлы «Совет районының Волочаевка урамындагы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кетү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә таянып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 3514 номерлы «Совет районының Волочаевка урамындагы җир кишәрлеге өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**